**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кыртапа авыл җирлегенең Иске Барыш авылында**
**2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

**21 ноябрь 2024 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Кыртапа авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәмәүчеләрдән һәм җирлек территориясендә тавыш бирү хокукына ия көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
1) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
3) торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.:
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы,Картапа авылы, Мәктәп урамы, 10 йорт, авыл клубы бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Барыш авыл җирлеге башлыгы И. Р. Җиһаншин